وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№12 (181). 22 март 2013 / 10-җөмәдиәләүвәл-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



*ФОАТ ХӘЗРӘТ:*
"Хәләл ул – халыкның сәламәтлеге, җәмгыятьнең киләчәге"
▷2◁



ХАЛКЫБЫЗНЫҢ АСЫЛ ЗАТЫ
▷3◁



ХАҖГА ЯКЫНАЙТА ТОРГАН ӨЧ АДЫМ
▷4◁



# КЕМ УЛ КАМИЛ СӘМИГУЛЛИН?

**Мөфти вазыйфаларын вакытлыча башкаручы итеп куелган Камил хәзрәт Сәмигуллин турында төрле фикерләр ишетелә. Белгәнебезчә, 2012 елның июль аенда булган терактта мөфти Илдус хәзрәт Фәиз җәрәхәтләр алды. Күптән түгел сәламәтлегенә бәйле рәвештә ул мөфтилектән китте. Хәзер мөфти вазыйфаларын Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең фәнни эшләр буенча урынбасары булып эшләгән, Тынычлык мәчете имам-хатыйбы Камил хәзрәт башкара.**

## Кем соң ул Камил хәзрәт?

Хәзрәт хакында мәгълүматларны төрле интернет-чыганаклардан, аны белгән кешеләрдән тупладым. Камил хәзрәт республикабыз мөселманнары арасында дин тәгълиматын яхшы белүче һәм оста вәгазьче буларак мәгълүм. Шулай ук ул татарларның дини мирасы нигезен тәшкил иткән хәнәфи мәзһәбе, матуриди гакыйдәсенә таянган дин әһеле.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте җитәкчелеге вакытында акыллы һәм өметле хәзрәтне күреп ала, яшь булуына да карамастан, аңа башта нәшрият бүлеген җитәкләүне, аннары урынбасар вазыйфасын ышанып тапшыралар.


Камил хәзрәтнең биографиясенә игътибар итик әле. Ул 1985 елда туган. 11 яшендә мәчеткә йөри башлый. Өлкән сыйныфларда укыганда "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенә укырга керә. 2003 елда Махачкала шәһәрендә Төньяк Кавказ ислам университетында укый, соңрак Истанбулга китә.

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

# Иң яшь каллиграфка – 13 яшь

**Күптән түгел генә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Халыклар дуслыгы йортында гарәп каллиграфиясе конкурсының йомгаклау өлешен уздырды.**





Корьән укып башланган чарада катнашучыларны, кунакларны нәзарәтнең уку-укыту бүлеге мөдире Айдар Карибуллин, "Зәкят" хәйрия фонды җитәкчесе Сәетҗәгъфәр хәзрәт Лотфуллин һәм Халыклар дуслыгы йорты директоры Ирек Шәрипов, шулай ук жюри әгъзалары сәламләде.

"Конкурсны үткәрүне мәрхүм Вәлиулла хәзрәт Якупов башлап, оештырып җибәргән иде. Хәзрәтнең эше бүген дә дәвам иттерелүе һәм нәзарәтнең бу конкурска зур игътибар юнәлтүе күркәм гамәл", - дип билгеләп узды танылган каллиграф Нәҗип Нәккаш. Нәҗип ага Россия ислам институтының каллиграфия үзәге җитәкчесе Рамил Насыйбуллов һәм нәзарәт вәкилләре белән берлектә конкурста катнашучыларның эшләрен бәяләде.

Конкурста уннан артык кеше катнашты. Алдан җибәрелгән эшләр Халыклар дуслыгы йортының күргәзмәләр залына урнаштырылган иде. Моннан тыш Казанның Дәрвишләр бистәсендә урнашкан интернат-йортта тәрбияләнүче балаларның шамаилләрен карарга мөмкин иде.

Сәетҗәгъфәр хәзрәт әйтүенчә, шамаилләр ясарга өйрәнү кебек шөгыль балаларны мөселманнар - татар халкы мәдәниятенә якынайта һәм аларның сәләтләрен ачарга ярдәм итә.

Конкурста катнашучылар өч төрле бирем үтәде. Беренчедән, "Әл-Фатиха" сүрәсе аятьләрен төрле язу стилендә яздылар. Аннары төрле каллиграфик композицияләр ясадылар. Соңыннан каллиграфик үрнәкләрне укып күрсәттеләр.

Чара җиңүчеләрне игълан итү белән тәмамланды. Барлык катнашучыларга нәзарәтнең истәлекле бүләкләре өләшенде, ә җиңүчеләргә акчалата бүләк бирелде.

Гарәп каллиграфиясе конкурсында җиңүчеләр:

I урын -Әмир Билалов;

II урын - Анна Хәмидуллина;

III урын - Рәмзия Булычева.

Модерн стилендә башкарган эшләре өчен Әлфия Исхакова, классик юнәлештә - Әлмира Садретдинова бүләкләнде.

Иң яшь катнашучы 13 яшьлек Айзат Минһаҗевка кызыксындыру бүләге тапшырылды.

Конкурска тәкъдим ителгән шамаилләр Татарстан мөфтияте бинасында урын алачак.



## ЯҢАЛЫКЛАР

### ПРЕЗИДЕНТ "ДУМ РТ ХАДЖ" ПРОГРАММАСЫ ПРОЕКТЛАРЫН ХУПЛАДЫ

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте хезмәткәрләре, мөфтиятнең халыкара мөнәсәбәтләр бүлеге мөдире Руслан Нәфисуллин Татарстан Президентына кече хаҗ (гомрә) кылуда булышлык күрсәтте.** Мәгълүм булганча, 16 март көнне Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Согуд Гарәбстанына рәсми сәфәр кылды. Әлеге сәфәр вакытында Татарстан делегациясе, ислам дине кушканча, Мәккә шәһәренә килгәч гомрә кылды.

Әл-Хәрам мәчетендә төзекләндерү эшләре баруга һәм кайбер урыннарда хәрәкәт итү бик авыр булуга карамастан, Рөстәм Нургали улы һәм башка делегация әгъзалары ихластан гомрә хаҗы таләпләрен үтәде. Кече хаҗ ахырында Татарстанга бәрәкәт һәм шәфәгать сорап дога кылынды.

Моннан тыш, Рөстәм Миңнеханов белән Руслан Нәфисуллин татарстанлылар өчен хаҗ сәфәрен оештыру үсеше турында сөйләште. Президент Рөстәм Миңнеханов "ДУМ РТ Хадж" программасы кысаларында тормышка ашырылачак проектларны хуплады.

### МӨФТИЯТТӘ ПЛЕНУМ УТЫРЫШЫ УЗДЫ

**16 март көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Пленум утырышы булды.**

Пленумда республика мөфтие вазыйфасына рәсми кандидатлар расланды. Алар - Татарстан мөфтие вазыйфаларын башкаручы, 27 яшьлек Камил Сәмигуллин; Россия ислам килешүе ассоциациясенең Голәмалар советы рәисе, 43 яшьлек Фәрит Хәйдәров; Татарстан Эчке эшләр министрлыгы каршындагы Хәтер мәчете имамы, 85 яшьлек Харис Салихов.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Пленумы Кама буе төбәге казые Рөстәм хәзрәт Шәйхивәлиевның тәкъдимен кабул итте. Рөстәм хәзрәт Пленум утырышында: "Журналистлар, һәм башкалар да кандидатларга төрле сораулар бирәчәкләр. Менә шушы сорауларга җавап биргәндә бер-берегезне дә, элеккеге мөфтиләрне дә пычратмасагыз иде. Хәзер менә бер ай сайлау алды кампаниясе барачак. Динебезне, мөселманнарны каралткан сүзләр яңгырамасын, сайлау алды кампаниясе шәригать кысаларыннан чыкмасын иде", - дигән сүзләрен җиткерде.

### БӨГЕЛМӘДӘ ДИНИ ЙОЛАЛАРНЫ ДӨРЕС ҮТӘРГӘ ӨЙРӘТӘЛӘР

**Бөгелмә мөхтәсибәтендә җеназа йолаларын башкаручылар һәм дини мәҗлесләр үткәрүчеләр өчен курслар башланды. Мондый төр курслар районда соңгы биш елда даими үткәрелеп килә.**

Елга бер тапкыр уздырылучы курсларга быел утыздан артык өлкән яшьтәге кеше килгән.

***Мәгълүматлар Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

# КЕМ УЛ КАМИЛ СӘМИГУЛЛИН?

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

Анда Коръән өйрәнә. Фикъһе, фикъһе ысулы, гакыйдә, хәдис, хәдис ысулы, хөсне хат (матур язу), сарыф (морфология) һәм нәхү (синтаксис) буенча иснәд (Пәйгамбәребездән (сгв) башлап Әбу Хәнифә аша өзелми килгән чылбыр) белән иҗазәт (шәригать фәннәрен укыту өчен рөхсәт) ала. Икенче төрле әйткәндә, аның дини гыйлеме зур. 2008 елда Россия ислам университетының ислам фәннәре факультетына укырга керә. Шул ук вакытта 6 ышанычлы хәдис җыентыгыннан белем бирү өчен шәех Габдерәхим Сәет Ликрим бине Нәхилдән (Марокко) рөхсәт ала.

Гыйлем туплауга гаять зур омтылыш, ифрат тырышлык, Аллаһ ризалыгы өчен эшләү хәзрәтнең дәрәҗәсен үстерә. Студент елларыннан ук үзебезнең Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдин, Әхмәтһади Максуди, Габдеррәхим Утыз Имәни кебек татар дин әһелләре хезмәтенә, мирасына тартылуы да зур роль уйный. Хәзрәтнең телләр өйрәнү сәләте ачыла, ул гарәп һәм төрек телләрендә иркен сөйләшә.

2007 елда Төмән өлкәсе Нижневартовск районының бер бистәсендә имам булып эшли башлый. 2008 ел башында энергиясе ташып торган, әйдәп баручы (лидер) сыйфатларына ия һәм шул ук вакытта тыйнак, ягымлы хәзрәтне Казан шәһәренең Мирный бистәсендәге Тынычлык мәчетенә имам-хатыйб булып эшләргә чакыралар. Бик кыска вакыт эчендә яшьләр дә, өлкәннәр дә гади тел белән дин нигезләрен аңлатучы, ачык йөзле хәзрәтне яратып өлгерә.

Тырышлыгы һәм ихластан бирелеп эшләве белән Камил хәзрәт үзен югары дәрәҗәле белгеч, дин әһеле итеп күрсәтә. Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт тәкъдиме белән аны казый киңәшчесе итеп билгелиләр. Шулай ук ул Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Экспертлар советы җитәкчесе, Голәмалар шурасы һәм Президиум әгъзасы. 2011 елдан мөфтияттә нәшрият бүлеген җитәкли. Кыска гына вакыт эчендә "Һәркем хафиз була ала" ("Каждый может стать хафизом"), "Ислам сорауларда һәм җавапларда" ("Ислам в вопросах и ответах") (балалар өчен), "Мөхәммәдия касыйдәсе"н, "Бәдел Әмәли" гакыйдәсен, фикъһе фәне буенча "Зүбдәтел мәҗәллә", шулай ук "Карабаш" тәҗвиден, Әбу Хәнифәнең "Дурруль-Макнун" китапларын әзерли, тәрҗемә итә.

Камил хәзрәтнең дин өлкәсендәге уңышлары белән бергә аның әле гаилә башлыгы, өч бала әтисе булуы да сокландыра.

Хәзрәтнең үз эшенә чын күңелдән бирелгәнлеге, инсафлы, итагатьле булуы күренә. Ул Россия дин әһелләренең яңа буын вәкиле. Яшь буынны динне тирән белүләре, эшне үзенчәлекле итеп оештырулары һәм үзгәрешләргә омтылышлары аерып тора. Камил Сәмигуллинның Татарстан Диния нәзарәте һәм республика мөселманнары алдында торган бурычларны үтәвенә өмет зур дип әйтә алабыз.

**Айрат ХӘСӘНОВ**

## Фоат хәзрәт:

# "Хәләл ул – халыкның сәламәтлеге, җәмгыятьнең киләчәге"

**Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте фәрманы белән мөхтәсибәтләрдә хәләл ашамлыкларны тикшерү комиссияләре төзелде. Алар базарларга, сәүдә нокталарына рейдлар белән чыгарга һәм ялган хәләл продукцияне ачыкларга тиеш була. Бу нисбәттән "Нәрсә хәләл ризык, ул нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?" дигән сорау туа. Без бу сорауга җавап бирүне үтенеп, нәзарәттәге "Хәләл" комитетының баш эксперты Фоат хәзрәт Мөхәмәтовка мөрәҗәгать иттек. Ул аңа болай дип җавап бирде:**

- Хәләл белән хәрамне аеру мөселман өчен бик мөһим. Чөнки белә торып хәрам белән туклану - ул инде мөселман кешегә хас сыйфат була алмый.

Хәләл, хәрам дигәндә күбебез беренче чиратта ризыкны, мөселманча суелган яки суелмаган итне күз алдына китерә. Әмма хәләл төшенчәсе мөселман тормышының барча якларын да үз эченә ала. Ул - ризык куллануда да, көндәлек тормышыбызда да, дөрес итеп бизнес алып баруда да чагылыш таба... Башлыйк хәләл ризыктан. Алыйк хәләл итне. Аның хәләллеге суюдан башлана. Мал ничек суела да, кем тарафыннан чалына? Малны чалганда Аллаһ зикер ителәме (искә алынамы)? Динебездә мал чалу биш таләпкә буйсына:

1) мал чалучының мөселман булуы;
2) ир-ат булуы;
3) балигъ булуы;
4) үз акылында булуы;
5) Аллаһны зикер итүе - "Бисмиллаһи Аллаһу әкбәр" дип әйтүе.

Син тавык чаласыңмы, эре малмы - шул шартлар үтәлгәндә генә суелган малның ите, тиресе, эчке органнары хәләл була. Өстәмә таләпләр - мал таза, сәламәт булырга тиеш. Мал чалганда намаз уку, дога кылу кирәклеге хакында да еш кына ишетергә туры килә. Шәригатебездә андый таләпләр юк. Болары - халкыбызның күркәм гореф-гадәтләре. Шулай ук малны чалу урынына куркытмыйча алып килү, күкрәген кыйблага таба юнәлтү, 3 яисә 4 аягын бәйләү тиешле. Әмма болары үтәлмәсә дә, алдагы 5 шарт үтәлгәндә, ит хәләл була. Һәм "Хәләл" комитеты шушы 5 шартка таянып эш итә. Күләмгә килгәндә, бүгенге көндә ит комбинатлары үзләренең мөмкинлекләреннән чыгып эш итәләр. Кемдер көненә берничә баш кына мөгезле эре терлек суеп, аны эшкәртеп өлгерергә мөмкин, ә кемдер йөзәрләгән башны. Ә кошчылык фабрикалары исә дистә меңнәр белән генә эш итәләр. Һәм аларда электр тогы кулланмыйча мөмкин түгел. Әмма ул хәләллеккә шик тудыра алмый. Чөнки тавык яки башка кош электр шогына эләккәч йоклау хәлендә була, аның тереклек сыйфатлары югалмый. Төркиядә булдык - анда да, бездә дә, ут күршеләребез Башкортстанда да шулай эшлиләр.



*Фоат хәзрәт Чиләбенең "Равис" кошчылык фабрикасында киңәшмә уздыра.*

Инде шул суелган мал итеннән төрле тутырмалар ясауга килик. Биредә инде сораулар туа. Чөнки хәләл иттән ясалган тутырмаларда башка катнашмалар, шул исәптән тәмләткечләр дә хәләл булырга тиеш. Бүгенге көндә үсемлекләрдән ясалган тәмләткечләр дә, химик юл белән алынганнары да бар. Белгечләрнең бурычы - аларның каян чыкканын ачыклау, хәләллеген раслау. Бу очракта Голәмалар шурасы фәтвалары бик мөһим. Ниндидер шикле әйберләр булганда, без алардан фәтва алабыз. Фәтвалар интернет аша гарәп илләреннән дә үтеп керә. Кайберәүләр Йосыф Кардави фәтваларына таянып эш итә. Безнең фикеребез шундый: үзебездәге галимнәрнең фәтвасы буенча эш итәргә кирәк. Әйтик, шул ук Й.Кардави сыйфаты, халәте үзгәргәндә дуңгыз тиресе дә хәләл булырга мөмкин, ди. Әмма күңелдә шик кала. Безнең теләк - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендәге Голәмалар шурасы хәләллекне ачыклау мәсьәләләренә киңрәк тукталса, шурада хәләллек буенча аерым фәтва бирүче төркем булдырылса иде. Бу безнең өчен олы зарурлык. Чөнки Россия буенча шундый хәл: 3-4 җирдә хәләллекне раслаучы ширкәтләр бар. Кемдер: "Сертификат бирәбез", - ди, кемдер - шәһадәтнамә. Сертификатны дәүләт стандарты органнары гына бирә ала. Безнең комитет хәләллекне раслап шәһадәтнамә (таныклык язуы) бирә. Әмма безгә шундый хәлләр белән дә очрашырга туры килә: җитештерүченең сертификаты бар, ә күңелдә - шик-шөбһә. Тотынабыз тикшерергә. Мәсәлән, бер күргәзмәдә хәләл сарделькалар күрдем. Аның тышчасы нәрсәдән ясалуы белән кызыксындым. Миңа аның чын (натураль) булуын әйттеләр. Белүемчә, Россиядә бүген беркем дә тутырмалар өчен чын тышлыклар җитештерми. Ә алар миңа: "Безнең сертификат бар", - диләр. Шуңа күрә Татарстанга хәләл маркасы белән килүче һәр ризык безнең комитет тарафыннан расланырга тиеш. Бу мәсьәлә буенча мәгълүмат чараларында халыкның да фикерен ишетәсе килә.

Халыкта маргаринга, кулинар майга дуңгыз мае кушыла дигән фикер яши. Күптән түгел Түбән Новгородтагы бер зур май комбинатында булдык. Аның филиалы Самара шәһәрендә дә бар. Күрдек, искитмәле хәл. Барлык продукцияне, хәтта сабынны да фәкать үсемлек майларыннан гына эшлиләр. Анда рапс мае да, көнбагыш мае да, пальма мае да бар. Бүгенге көн технологиясе шундый - көнбагыш маеннан каймак эшләп чыгаралар. Шуңа күрә этикеткалар белән яхшылап танышырга кирәк. Әгәр дә продукция үсемлек маеннан эшләнгән икән - биредә шик калмый.

Бүгенге көндә хәләл тортлар, башка кондитер әйберләре кулланылышка керде. Аларга төп таләп - составларында исерткечләр булмау. Икенчедән, кулланылучы май хәләл, ягъни үсемлек мае булырга тиеш. Тортларны ясаганда желатин кулланыла. Ул хайван сөягеннән кайнатып ясалган матдә. Желатин хәләл тортлар составында булырга тиеш түгел. Күп кенә җирләрдә аны хәзер диңгез үсемлекләре белән алыштыралар.

Ипи нигездә хәләл. Әгәр дә ипигә төрле тәмләткечләр кушыла икән, ул вакытта яхшылап карарга кирәк.

Кайбер галимнәрнең фикере шундый: әгәр коньяк яки ром тәмләткечләрне эретү өчен генә кушыла һәм ул күпмедер вакыттан соң очып бетә икән, аны куллану ярый. Бу мәсьәлә буенча анык фикер юк. Шуңа күрә без әйтәбез: шикле әйберләрне кулланырга ярамый.

Сөт турында. Халыктан җыелган, фермалардан китерелгән сөт, әлбәттә, хәләл, без аның һәм аңардан ясалган каймакның, эремчекнең хәләллегенә берничек тә шикләнә алмыйбыз. Ә менә алты ай дәвамында әчеми торган сөткә килсәк, монда сораулар туа. Чөнки нинди генә яхшы шартларда сакланса да, 5-6 көн эчендә сөт әчи. Шуңа күрә бу очракта хәләллекне ачыклау зарур.

Бүгенге көндә дөнья буенча хәләл ризыкның әйләнеше триллион долларлар белән исәпләнә. Бу бик зур сан.

Хәләл җитештерү Россиядә дә кызу темплар белән үсә. Мәсәлән, "Чаллы-Бройлер" җәмгыяте 2004 елны 40 тонна тавык ите чыгарган булса, былтыр бу сан 6500 тонна тәшкил итте. Элек хәләл итне авыллардан эзләсәк, хәзер хәләл индустрия бар. Чөнки хәләл ризык ул - бәрәкәт, тазалык дигән сүз. Ул халыкның саулыгы, җәмгыятьнең киләчәге. Хәзерге вакытта

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# ХАЛКЫБЫЗНЫҢ АСЫЛ ЗАТЫ

***(Мәрхүм Ризаэтдин Фәхретдин хәзрәтләренә мәрсия)***

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**Тарихыбыз күгендә якты йолдыз булып кабынган, якты йолдыз булып янган, халкыбызның хәтере күгендә якты йолдыз булып хатирәсе сызылып калган затларыбыз байтак, Аллага шөкер. Аларга Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!**

Шундый каһарман бабаларыбыздан Ризаэтдин Фәхретдин хәзрәтләре мөфти буларак та, тарихчы буларак та, мәгърифәтче буларак та аеруча әһәмиятле урын били. Бу затның яшәеше, саф әхлагы, һәм тарих галиме булуы, һәм мулла, имам-хатыйб булуы, килеп кичкән мөфтиләр арасындагы иң намуслы, иң мәгълүматлы шәхесләрдән булуы, казый буларак та гаделләрнең гаделе булып милләтебезгә хезмәт итүе буыннардан-буыннарга риваять ителерлек бер якты үрнәк хасил итәдер.

Ризаэтдин Фәхретдин 1859 елның 4 гыйнварында (ягъни 17 гыйнвар көнне) элеккеге Самара губернасының Бөгелмә өязенә керә торган Кичүчат авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Бу авыл хәзер Татарстанның Әлмәт районына карый. Нарасый Ризаэтдин әнисе Мәхүбә белән атасы Сәйфетдин хәзрәттән сабак ала. Башлангыч белемне алганнан соң, аны Түбән Чыршылы авылына илтеп куялар. Менә шушы вакытларда ук инде аның белем куәсе, галимлек куәсе ачыла бара: ул китаплар күчереп язу эше белән бик нык мавыгып китә. Аның ул кульязмалары Уфа архивларында саклана. Алар арасында Шиһабетдин Мәрҗанинең "Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар" китабының әүвәлге нөсхәсе дә бар. Ихтимал, менә шушы китапны кулдан күчереп язганда Ризаэтдин шәкерт Шиһаб хәзрәтнең шәхесенә, аның иҗатына гашыйк була. Һәм Ризаэтдин Фәхретдин хәзрәтләре әнә шул шәкертлек елларыннан алып үзе остаз дәрәҗәсенә менеп җиткәнче бөек аксакалыбыз Шиһабетдин хәзрәтләренең йогынтысында иҗат итә. "Шәкерт остазын узып китә алмаса, остазның остазлыгында шик бар" ди халык мәкале. Дөньякүләм шөһрәт казанган остаз Шиһабетдиннең иҗаты да чиксез мактауларга лаек, ул калдырган мирасны өйрәнеп, өйрәтеп чыгу үзе генә дә бер университет булыр иде. Эшләгән эшләренең нәтиҗәлелеге, күләме һәм каләме белән яктырткан хезмәтләре, ислам дине фәлсәфәсе буенча, мәгърифәт өлкәсендә, мөгаен, Ризаэтдин Фәхретдингә тиңнәр юктыр да. Аның каләме аша узган һәм һичкайчан да әһәмиятен югалтмый торган әсәрләр дистәләгән томнар тәшкил итә. 1887-1888 елларда гына да ул бая санап киткән кульязма китапларыннан тыш "Әттәхфәтеләнсия", "Китабәт-тәсрыйф", "Китабе мөкаддимә", "Китаб-ел игътибар" исемле китаплар яза.



1887 елда остазыбыз, уңышлы рәвештә имтиханнар тапшырып, имам дәрәҗәсенә күтәрелә. Бу вазыйфаларын үтәгән вакытта Ризаэтдин хәзрәт галим-голәма, имамнар, мөселманнар каршысында абруй казана, һәм 1891 елда аны Диния нәзарәтенә казый итеп куялар. Бу гамәл Ризаэтдин Фәхретдинне бәхетле итә. Монда ул фән белән иркенләп шөгыльләнә башлый. Шушы елларда ул "Сәлимә" һәм "Әсма" хикәяләрен яза. Шуннан соң инде аның исемен мәңгеләштерә торган әсәрен башлый. "Асар" исемле бу энциклопедик хезмәт Болгар чорыннан алып XX гасырга кадәр яшәгән, иҗат иткән, падишаһлык кылган каһарман бабаларыбыз турында бәһаләп бетергесез күп мәгълүматны үз эченә ала. Монда меңнән артык шәхеснең тәрҗемәи хәлләре һәм башка кыйммәтле хәбәрләр тупланган. Бу хезмәте Ризаэтдин Фәхретдин хәзрәтләрен дөнья тарихчылары рәтенә куя.

Тарихчыбыз Риза казый ислам нигезләрендә тәэселгән мәгариф, тәрбия китаплары да иҗат итә. "Тәрбияле бала", "Тәрбияле ана", "Тәрбияле ата", "Нәсыйхәт", "Шәкертлек әдәбе", "Коръән вә тәбакать", янә тарихка кагылышлы "Мәшһүр хатыннар", "Исмәгыйль сәяхәте" һәм башка бик күп әсәрләрен дөньяга чыгара.

Ризаэтдин Фәхретдин киң эрудицияле галим була. Ул Шәрекъ ислам тәгълиматына гына ябышып ятмый, аның иҗатында Сократ та, Аристотель дә, Дәрдемәнд тә, урыс халкының алдынгы фикерле шәхесләре Бартольд та, Крачковский да, Карамзин да урын алган. Ул алардан өйрәнгән һәм кирәк чакта аларның житешсез, хәтта гөнаһлы хаталарын да тәнкыйть утлы астына алган. Фәхретдин хәзрәтләре намуслы, саф, гадел тарих ясарга күп көч куйган бабыз.

Шулай итеп, Риза казый, күрсәткән олуг хезмәтләренә күрә, 1922 елда мөфти вазыйфаларына чакыртыла. Бу вазыйфаның никадәр җаваплы, никадәр кыен булуына карамастан, Ризаэтдиннең галимлеге аңа тыгылык бирми, ул төннәрен йокламаса да, ял көннәрендә ялын кисеп булса да фәнгә хезмәт итә. Ислам дине галиме буларак та, тарихчы буларак та эшен туктатмый, Ибн Фадлан, Батута кебек сәяхәтчеләрнең сәяхәтнамәләрен рәткә сала, үзенең энциклопедик әсәре "Юаныч"ны тәмамлый.

Олуг шагыйребез Габдулла Тукай Ризаэтдин Фәхретдиннең дин өлкәсендәге эшчәнлегенә югары бәя биргән. Ул 1912 елда болай ди: "Әгәр Русиядә Коръән тәрҗемә ителергә кирәк булса, мөтәрҗимлеккә иң муафикъ кеше - Риза казый. Чөнки ул "Әсма", "Сәлимә" кеби китаплары белән куә-и тәхрия вә хәтта шигърияусен күрсәткән вә гомумән ифадәсе ачык, язу тарызы садә вә гүзәл бер язучыдыр". Ни аяныч ки, бу изге эшкә, Коръәнне татарчага тәрҗемә итәргә, Ризаэтдин Фәхретдиннең вакыты житми.

Беренче тапкыр казый булып торганында, 1890 елларда, Р.Фәхретдин янына мәшһүрлек казанган шагыйрь Акмулла килә. Атаклы сәйях, казакъ арасында да, башкортларда да, татарлар янында да мәшһүрлек казанган Акмулла бу юлы Риза казый янына шагыйрь бәйгесе, акынлык, чичәнлек ярышы узгару максаты илә килми. Күп җәфалар, зинданнар кичкән остаз олы кайгы күтәреп килә казый янына. Аның сөекле хатыны талак та көтмәенчә ире Акмулладан аерылып китә. Сәяси яктан да, дошманнары тарафыннан да күп кыйналган шагыйрьгә сөекле кешесез калу бик тә хәтәр ялгызлык була. Ялынулар, үгетләр дә ярдәм итмәгәч, Акмулла Риза казый янына олы өметләр белән килә. Хатынымны кайтарырга фәтва язып бир дип ялвара. Казый кешегә, ир кешене яклап, талак алмаган көенчә качып киткәне өчен җәзага тарту, хатынны кире ир йортына кайтару өчен фәтва язып бирү кыен да булмаган булыр иде. Ләкин Риза казый коры казый гына түгел, ул - тәрбияче, ул - мәгърифәтче, ул - психолог, ул - философ. Бөек остазыбыз коры хокукчы гына булмаган, ул бөтенләй башка карар чыгара. Кискән икмәк кире ябышмас, бу кайгыны син ирләрчә күтәр, ир-җегет булып йөрәк җәрәхәтеңне кысып түз, үзеңне сөймәгән хатынны ирексезләмә дигән кебек киңәш бирә. Кайгы баскан, өмете өзелгән шагыйрьнең күңелен күтәрер өчен, Риза казый Уфада шагыйрьләр, чичәннәр, акыннар бәйгесе оештыра. Бу бәйгегә бирелеп, Акмулла кайгысын оныта кебек. Һәм бу киңәшләре, бу изге теләктәшлеге өчен Акмулла Риза казыйга рәхмәт йөзеннән үзенең яңа китабын җибәрергә вәгъдә итә. Ләкин бу китап казыйга килеп ирешә алмый, озакламый Акмулла катилләр тарафыннан юлда үтерелә. Авыр туфрагы җиңел булсын, урыны җәннәттән әйләсен!

Шушы вакыйгадан Риза казыйның никадәр дә олы җанлы, демократик хокукчы икәнен без ап-ачык күрәбез.

Ризаэтдин Фәхретдин дин кагыйдәләрен, мөселманнарның яшәү рәвешен аңлатканда хәдисләр белән генә чикләнми, ул үз тәҗрибәсеннән, үзе шаһит булган вакыйгаларны кулланып, савап казануны аңлата. Сәдакаларны, хәерне сорап алу, биргән сәдакадан канәгатьсез калу, хәтта: "Миңа сәдаканы аз бирде", - дип карганып йөрүчеләргә карата остазыбыз менә ничек яза: "Мөҗавирләрнең олугларыннан булган бер адәмнең: "Бәлки, Әби патшаны яудырыр (йөзлек кәгазьдән киная кыла) дип фәлән кешегә барган идем, бары егерме бишлек бирде, кызармады вә игътизар да (гафу үтенү) кылмады", - дип сөйләве риваять ителә..."

Ягъни, бу мөҗавир бер байдан Екатерина патшабикә бастырган йөзлек акча өмет итеп, бары тик егерме бишне генә ала алган икән дә, шуңа канәгатьсез булып, сәдака бирүчене хурлап йөри икән.

"Без укыган урында, - дип яза остаз, - мәдрәсә өйләрендән беренең мичe җимерелгән сәбәпле, шәкертләр салкында торып җәфаландылар. Октябрь башлары булып, көннәр салкын иде. Бер-ике сум акча юклыктан шәкертләрнең салкында торулары аңлаучы мосафир бер карт, чишенеп, үзе мич чыгарырга керешә. Шәкертләр кайсы ком, кайсы балчык, кайсы су китерделәр, вә һәрбере бер хезмәт белән йөгереп йөриләр иде. Тәүлек ярым дигәндә морҗага яктылар, күбесе күпер башларыннан вә чүплекләрдән җыелып алган кирпеч ватыкларыннан өелгән мич могҗиза кабилендән бик килештә вә кыза торган булды. Шәкертләр шатландылар вә: "Бабай, сиңа нинди дога кылыйк?" - диештеләр. Бабай: "Минем максудым бер генә нәрсә - үлдыр кем дөньядан иман берлә үтү, шуны сорасагыз булды!" - диде. Шәкертләр беравыздан кычкырып дога кыла башладылар, бабай үксеп-үксеп елый иде.

Егерме биш сум кәгазьне акчага санамаган кешегә игелек итеп, җәннәтне сатып алуга күрә бер тәңкәлек мич бәрабәренә сатып алу өмидлерәк". Мисал тәмам.

Нинди гүзәл хикәя! "Сәдака ничек бирелергә тиеш?" дигән сорауга үтемле җавап. Ризаэтдин Фәхретдиннең иҗаты әнә шулай зиһен белән гүзәллек үрелеп барган бер иҗаттыр.

Сүзләремә ышандырыр өчен, мин бөек остазның, һич югында, ике китабын - "Болгар вә Казан төрекләре" һәм "Җәвамигуль-кәлим" әсәрләрен укып чыгуыгызны үтенәм.

Менә шундый ул безнең асыл зат, акыл иясе Ризаэтдин Фәхретдин хәзрәтләре.

Шәмнең яктысы шәмдәлнең төбен яктыртмый, шәмнең яктылыгы үзеннән ерак араны яктырта. Ризаэтдин Фәхретдин иҗатының нуры да вакытлар узган саен яктырак булачак.

Мәрхүм остазыбыз, тарихчы-галим, мәгърифәтче-имам, акыллы мөфти, гадел казый, саф әхлак иясе Ризаэтдин Фәхретдин хәзрәтләренең гүре нур булсын, урынын җәннәттән әйләсен! Аңа Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте һәм сәламнәре булсын! Амин!

**Рабит БАТУЛЛА,**
**Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе,**
**Татарстанның халык язучысы**

**P.S.** *Язучы, җәмәгать эшлеклесе, "Коръән аятьләренең татарча мәгънәләре"н бастырып чыгаручы Рабит (Роберт) Батулланың 26 мартта туган көне - 75 яшьлек юбилее. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте республикабызның барлык мәчет-мәхәлләләрендә хезмәт куючы дин әһелләре исеменнән сезне гомер бәйрәмегез белән тәбрик итә һәм исәнлек-саулык, шатлык-куанычлар, иҗади уңышлар тели. Татар-мөселман өммәте өчен башкарган хезмәтләрегез Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтендә булып, милләтебезнең тарихи язмышын сурәтләүдә, халкыбызның бөек уллары турында истәлекләр язуда Аллаһ Раббыбыз сезгә көч-куәт биреп, дәвамчыларыгызны калдыруны да насыйп вә миссәр кылса иде.*

## Фоат хәзрәт: "Хәләл ул – халыкның сәламәтлеге, җәмгыятьнең киләчәге"

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

хәләл ризыкларны башка диндәгеләр дә куллана. Чөнки хәләл ризыкның файдасын алар үз мисалларында аңлый. Әмма әле Татарстанда хәләл продукция аңа булган ихтыяҗның 20-25 процентын гына канәгатьләндерә, ә Россия буенча бары тик бер процентны гына.

Безнең хәләл продукция ни өчен башка илләргә чыгарылмый? Шундый сорау бирүчеләр дә бар. Әлбәттә, хәләл продукцияне чит илләргә чыгару өчен теләк кенә җитенкерәми, ул җитештерүчеләр өчен файдалы да булырга тиеш. Бүгенге көндә бездә җитештерелгән тавык ите Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендәгедән ике мәртәбәгә кыйммәтрәк. Чөнки, алар белән чагыштырганда, безгә җылылык өчен дә зур чыгымнар тотарга кирәк. Шулай ук башка технологик сәбәпләр дә бар.

Хәләл ризыкларның популярлашуы кайбер намуссыз җитештерүчеләрнең хәләл булмаган продукцияләрен хәләл маркасы астында чыгаруга китерә. Шул сәбәпле, узган елның июнендә мөфти Илдус хәзрәт Фәиз фәрманы белән мөхтәсибәтләрдә хәләл ашамлыклар өчен җаваплы кешеләр билгеләнде. Ә быел җәмагать башлангычында эшләячәк комиссияләр төзелде. Алар базарларга, сәүдә нокталарына рейдлар уздырачак. Билгеле, алар кискен чаралар күрә, хәләл булмаган продукцияне каядыр чыгарып ташлый алмый. Әмма хәләллекне раслаган документлар булмаган очракта, комитетка хәбәр бирергә, бу хакта мәгълүмат чаралары аша халыкка җиткерергә мөмкиннәр. Минемчә, бер җитештерүче дә мондый хәлдә калырга теләмәс. Чөнки мәгълүмат чаралары аша кисәтү булгач, бу сәүдә ноктасына килүчеләр кимиячәк. "Кулланучыларның хокукларын яклау турында"гы Законның 10 нчы маддәсендә әйтелгәнчә, ризыкка ниндидер яңа сыйфат, үзенчәлек бирелгәндә аны раслату кирәклеге искәртелә. Шуңа күрә комиссия әгъзалары кулланучыларны яклау хезмәтләренә дә мөрәҗәгать итә ала. Минемчә, мондый рейдларны Роспотребнадзор хезмәткәрләре белән бергәлектә уздыру нәтиҗәлерәк булыр иде.

Киләчәктә хәләл җитештерүчеләргә ярдәм итү, хәләл кулланучыларны яклау җәмгыятьләре дә барлыкка килер дип әйтә алам. Алар рәсми теркәлергә, үз Уставлары, нигезләмәләре (положение) буенча эш итәргә мөмкиннәр. Бу Хөкүмәт органнарына бер ярдәм булачак.

Тагын бер нәрсә - экология һәм хәләл. Алар киләчәктә бергә эш итәрләр дип уйлыйм.

Әмма күңелне борчыган күренешләр дә бар. Татарстанда Агросәнәгать паркы ачылды. Аңа 72 оешма хәләл продукция белән керергә теләк белдергән. Сорау туа: аларның хәләллеген кем тикшергән дә, кем раслаган? Әлегә аларның комитетка мөрәҗәгать иткәннәре юк.

### Котлыйбыз!

Күптән түгел генә Мамадыш районы Югары Яке авылында яшәүче **Рәшит хәзрәт ХӘСӘНОВ**ка **75 яшь** тулды.

Хөрмәтле Рәшит хәзрәт! Сине олы юбилееӊ белән ихлас күңелдән котлыйбыз. Сине ярдәмчел, сабыр, киң күңелле, олы җанлы, кешелекле булуың өчен без барыбыз да хөрмәт итәбез. Гел шундый булып кал! Саулык-сәламәтлек, күңел тынычлыгы, балалар игелеге телибез. Соңгы сулышка кадәр Аллаһы Тәгаләнең тыйганнарыннан тыелып, кушканнарын үтәп яшәргә, изге гамәлләр кылырга, ике дөнья бәхетенә ирешергә насыйп булса иде.

*Синнән күчкән яктылыктан,*
*Нур сибелә тирә-юньгә.*
*Кайгы-хәсрәт күрми генә,*
*Яшик шулай бергә-бергә.*

**Иң изге теләкләр белән барлык имамнар, абыстайлар, дин әһелләре исеменнән Мамадыш районы имам-мөхтәсибе Илһам хәзрәт МИҢНЕГАЛИЕВ.**

# ХАЖГА ЯКЫНАЙТА ТОРГАН ӨЧ АДЫМ



**Хаҗ кылу культурасын күтәрү, хаҗиларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү, хезмәт күрсәтүне камилләштерү һ. б. буенча без даими рәвештә эш алып барабыз. "ДУМ РТ Хадж" операторының тәҗрибәгә тиң беренче нәтиҗәләре, Аллаһның рәхмәте белән, бик уңышлы булды.**

Ләкин моның белән генә тукталып калу дөрес булмас, шуңа да без сезнең тәкъдим-киңәшләрегезне исәпкә алып, хаҗ кылу өчен җавап бирә торган алдынгы оешмаларның тәҗрибәсен өйрәнәбез. Узган ел без булачак хаҗиларны алдан ук хаҗ кылу тәртибе белән таныштырдык һәм шул максат белән Казанда һәм республикабыз районнарында курслар оештырдык. Быелгы курслар тагын да югарырак дәрәҗәдә узар дип көтелә. Хаҗ буенча билгеле бер фикер-нәтиҗәгә килмәгән яисә хәзерге вакытта финанс ягы такыр булган кешеләр өчен, аларны да хаҗ гыйбадәтенә якынайту ниятеннән, берничә киңәш биреп узасым килә.

## Ният кылу

Хаҗ кылырга теләгән һәр мөселман кешесе иң беренче чиратта ният кылырга - аның әһәмиятен аңларга һәм шул теләк белән янарга тиеш. Мондый фикер-нәтиҗәгә килгәннән соң, хаҗ сәфәре артыннан йөри башларга да мөмкин дигән сүз. Дөрес нияттән башка башланган хаҗ үзенең асылын һәм кыйммәтен югалта. Үз-үзегезгә сорау бирегез - сезнең нилектән хаҗга барасыгыз килә? Җавап гади: сезне Аллаһы Тәгалә Үзенә кунакка чакыра. Моннан да мөһимрәк - ягъни бары тик тиешле гамәлләрне изге җирләргә барып кылудан да әһәмиятлерәк - берәр нәрсә була аламы соң? Аллаһы Тәгалә берәүгә дә күтәрә алмаслык йөк бирми. Әгәр дә сезгә үзегез эшләгән компаниянең оештыручысы яки аның башлыгы чакыру җибәрсә, сез аны кире кагачаксызмы? Әлбәттә, юк! Сез дулкынлана-дулкынлана һәм киләчәктә аңа зур өметләр баглап очрашуга китәчәксез. Әгәр дә сезне барлык хуҗаларның Хуҗасы, аларның да җитәкче-мөдирләрен Дөньяга бар кылучы чакырса?

## Мөмкинлекләр турында уйлану

Әгәр дә финанс мөмкинлекләре бердәнбер киртә булып тора икән, бюджетыгызны дөрес итеп төзү турында уйланыгыз. Бик аз кеше генә бүген хаҗ кылырга ниятләп, иртәгә үк юлга чыгып китә ала. Күпчелек кеше өчен ул - акча җыя-җыя күп еллар аңа әзерләнүдән гыйбарәт. Без сабырлыгыбызны югалтырга тиеш түгелбез. Кемнәрнеңдер сәфәрне каплый алырлык көчемсез милке булырга мөмкин, ә кемдәдер анысы да юк. Һәрвакыт кечкенәдән башлагыз. Сатып алырга теләгән әйберләрне кулга төшерү алдыннан яхшылап уйланыгыз - бәлки сез аны хәзергә үзегездә булдырмыйча торып та, акчаны хаҗ кылу өчен янда калдыра аласыздыр. Көн аралаш яки атна саен тиенләп акча җыеп кына, әлбәттә, тиз арада зур суммалар туплап булмаячак, ләкин һәр яхшы башлангыч хаҗга акча җыю өчен этәргеч булып тора. Шулай да Аллаһы Тәгаләнең сораган кешегә бирә торган Юмартлыгы (әл-Кәрим сыйфаты) - бигрәк тә яхшы эшләр башкаручылар өчен булуы - турында истән чыгармагыз. Хәрәкәтләнергә, сәбәбенә керешергә һәм Аллаһы Тәгаләдән сорарга гына кирәк. Барысы да бик гади.

## Хаҗ кылуның югары рухи баскычына кадәр үсеп җитү

Әлеге сәфәргә бару өчен күпләрнең акчаны янга калдыру юлы белән җыйганына шатланырга гына кирәк: без шул вакыт аралыгын нәтиҗәле итеп файдалана - кирәкле акчаны каян-ничек табу турында баш ватудан тыш, үзебезне рухи яктан әзерли, ягъни гыйлем җыя алабыз. Без үзебезнең кылган эшгамәлләребезне, хаҗ безне тагын да тәкъвалырак итсен өчен, нәрсәләр эшләргә кирәклегебез турында уйланырга тиеш. Башка сәфәрләрдән аермалы буларак, хаҗ физик яктан да, рухи яктан да бер үк дәрәҗәдәге сәфәр булып тора. Шуңа күрә эчке һәм тышкы әзерлекләрне без хаҗ кылу өчен күп вакыт кала башларга тиеш. Финанска кагылышлы экономияләүләрне кечкенә адымнар белән башлаган кебек үк, рухи чистарынуыбызны да без зур булмаган адымнардан башларга тиешбез. Шулай итеп, әгәр дә без узган елда хаҗ кыла алмаганбыз икән, аны икенче елга планлаштыра башлыйк, һәм моның өчен бар көчебезне куйсак һәм сабырлык күрсәтсәк, иншә Аллаһ, хаҗыбызны башкара алырбыз!

***"ДУМ РТ Хадж" белән түбәндәге телефоннар аша элемтәгә керергә мөмкин: +7 (843) 524-92-10, +7 (843) 240-53-98, +7 (843) 200-93-11.***


***АДРЕСЫБЫЗ: 420021 Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 3 нче йорт.***

***Интернеттагы сайт:* www.dumrt-haj.ru.**

***Электрон почта адресы:* 5249210@gmail.com.**

**Хәбибулла (Руслан) НӘФИСУЛЛИН,**
**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең халыкара бүлек мөдире, "ДУМ РТ Хадж" программасы җитәкчесе**

## "САБЫЙГА" АКЦИЯСЕНДӘ КАТНАШЫЙК!



**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте "Татар радиосы" һәм Бөгелмә мөхтәсибәте белән берлектә, әти-әниләре ташлаган сабыйларга подгузник, пелёнка кебек кирәк-яраклар җыю максатыннан, "Сабыйга" дип аталган хәйрия акциясе уздыра.**

**Сабыйлар Бөгелмә районы балалар хастаханәсендә урнашкан "социаль койкалар"да сәламәтләндерү һәм тернәкләндерү курслары үтә. Мондый курсларны алар 30 көн эчендә үтеп бетәргә тиеш, ләкин тормыш күрсәткәнчә, әлеге вакыт аралыгында гына моңа ирешеп булмый, шунлыктан дәвалану берничә айга сузыла. Балаларны урнаштыру буенча аларның хокукларын кайгырту (опека) бүлеге шөгыльләнә, алар балага яңа әти-әни табып бирә яки аны якындагы балалар йортына урнаштыру җаен карый. Уртача алганда, ай дәвамында балаларның "социаль койкалар"ыннан дистәгә якын сабый уза. Әлеге сабыйлар үзләренең әти-әниләре тарафыннан кире кагылсалар да, җир йөзендә ярдәм кулы сузарга әзер торучы мәрхәмәтле кешеләр аз түгел. Барчагызны да сабыйлар гомеренә битараф калмаска чакырабыз.**

**Акция 2013 елның 31 мартына кадәр уза. Балаларга ярдәм итәргә теләүчеләр бала карау әйберләрен Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенә китерә ала.**

**Адресыбыз: 420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт, хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлеге.**

**Элемтә өчен телефон: +7 (843) 264-61-58, 89872639889 (Гөлнара Садыйкова).**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 12 (181) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35395.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция һәм нәшер итүче адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27. "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе. Язылу индексы - 16046.
***График буенча бу санга 21 март көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**